ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 ноябрь 2016 ел № 5791

2017-2019 елларга муниципаль яшьләр
программасын раслау турында

Яшьләрне социализацияләү һәм үз-үзләрен нәтиҗәле реализацияләү өчен шартлар тудыру максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 декабрендәге 7511 номерлы карары, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең Дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен раслау турында» 2014 елның 29 ноябрендәге 2403-р номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясендә тәрбияне бирүне үстерү Стратегиясен раслау турында» 2015 елның 29 маендагы 996-р номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең Дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен тормышка ашыру буенча чаралар планы турында» 2015 елның 12 декабрендәге 2570-р номерлы боерыгы, Россия Федерациясе хөкүмәтенең «2016-2020 елларга Россия Федерациясе гражданнарына патриотик тәрбия бирү» дәүләт программасы турында» 2015 елның 30 декабрендәге 1493 номерлы карары, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы законы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. 2017-2019 елларга муниципаль яшьләр программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә 2017-2019 елларга муниципаль яшьләр программасында каралган чараларны финанслауны «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 2017 – 117663,63 мең сум, 2018 – 118026,82 мең сум, 2019 – 118366,66 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарлары Р.М. Хәлимовка, Ә.А. Галиәкбәровага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы В.А. Гаврилов

Башкарма комитетның
2016 елның 3 ноябрендәге
5791 номерлы карарына
кушымта

# 2017-2019 елларга
# муниципаль яшьләр программасы

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре

# I кисәк. Гомуми нигезләмәләр

## 1 бүлек. 2017-2019 елларга муниципаль яшьләр программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2017-2019 елларга муниципаль яшьләр программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү нигезләре | «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең Дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен раслау турында» 2014 елның 29 ноябрендәге 2403-р номерлы боерыгы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясендә тәрбия бирүне үстерү Стратегиясен раслау турында» 2015 елның 29 маендагы 996-р номерлы боерыгы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең Дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен тормышка ашыру буенча чаралар планы турында» 2015 елның 12 декабрендәге 2570-р номерлы боерыгы;<br>«2016-2020 елларга Россия Федерациясе гражданнарына патриотик тәрбия бирү» дәүләт программасы турында» 2015 елның 30 декабрендәге 1493 номерлы карары;<br>Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы законы |
| Программаны төп эшләүче | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Программаның координаторы булып Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе тора.<br>Төп башкаручылар: Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитет районнар хакимиятләренең мәгариф, мәдәният һәм яшьләр белән эшләү бүлекләре, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе |
| Программаның максаты | Яшьләрне социализацияләү һәм үз мөмкинлекләрен нәтиҗәле тормышка ашыру өчен шартлар тудыру |
| Программаның бурычлары | - Балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең ялын оештыру; |

<table>
<tr><td></td><td colspan="5">- Яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең асоциаль һәм деструктив тотышларын профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар оештыру, социаль-куркыныч хәлдәге балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү;<br>- Яшьләрне вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">2017 - 2019 еллар</td></tr>
<tr><td rowspan="6">Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>1 нче ел/ мең сум</td><td>2 нче ел/ мең сум</td><td>3 нче ел/ мең сум</td><td>Барлыгы мең сум</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>117663,63</td><td>118026,82</td><td>118366,66</td><td>354057,11</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td colspan="5">Программаны тормышка ашыруга тотылучы чыгымнар күләменә шәһәр бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, инфляция процесслары һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге икътисадый хәлдән чыгып, төгәллекләр һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре</td><td colspan="5">Программа клуб берләшмәләре һәм программа белән җәлеп ителгән 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге мәшгуль яшьләрнең чагыштырма авырлыгын яшьләрнең гомуми санына карата 76,5 % итеп сакларга мөмкинлек бирәчәк</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруга контрольне оештыру системасы</td><td colspan="5">Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысулы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Нәтиҗәле дәүләт яшьләр сәясәте – ил үсешенең, гражданнарның тормыш дәрәҗәсен күтәрүнең һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрне камилләштерүнең иң мөһим инструментларының берсе.

Хәзерге дөнья бик актив һәм тиз үзгәрә. Үзгәрешләр кешеләрдә дә, беренче чиратта яшьләрдә бара. Яшьләрнең актуаль проблемалары бөтен җәмгыятьнең камил булмаганлыгын һәм кимчелекләрен чагылдыра. Шуңа

күрә бу кыенлыкларны хәл итү бөтен социумның муллыгына йогынты ясаячак.

Тормыш перспективалары булмаганлыктан, күп кенә яшь егетләр һәм кызлар криминаль дөньяның бер өлешенә әвереләләр. Гаиләләрнең социаль яктан тәэмин ителмәве, эш эзләү зарурлыгы яшьләрнең мәдәниятенә һәм белеменә йогынты ясый: алар белем алудан, рухи идеаллардан ераклаша.

Түбән тормыш шартлары, реализацияләү мөмкинлеге булмау яшьләрне спиртлы эчемлекләр һәм наркотиклар татып карарга этәрә. Яшьләр арасында эчкечелек һәм наркомания проблемасы бүгенге көндә иң актуаль проблемаларның берсе булып тора.

Яшьләр арасында тәмәке тарту проблемасы да аз түгел. Алар арасында тәмәке тарту турында хаталы фикер яшәп килә, ягъни, ул «модалы» булып күренә һәм үзен ирекле хис итә.

Яшьләрнең тормыш дәрәҗәсе түбәнәю аларның мәдәни тормышында да чагыла. Тормышка карата көнбатыш идеяләре дә популяр, алар мода һәм акча культында, матди байлыкка омтылуда, канәгатьлек алуда чагылыш тапты.

Моннан тыш, яшьләрнең ялын үткәрүдә дә проблемалар бар. Күп кенә шәһәрләрдә һәм авылларда буш вакытны культуралы үткәрү өчен шартлар тудырылмаган: бушлай бассейннар, спорт секцияләре яки кызыксыну буенча түгәрәкләр юк.

Югарыда күрсәтелгән проблемаларны хәл итү өчен, Яр Чаллы шәһәрендә 4 яшьләр үзәге («Заман», «Шатлык», «Орион», «Нур»), 26 яшүсмерләр-яшьләр клублары, «Экстрим-парк» һәм 4 социаль учреждение («Диалог» ППЯҮ, «МТД», «СЯЭҮУ», «Форпост» ҖТСбЯБҮ) үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра. 2016 елга шәһәрдә 26 яшүсмерләр-яшьләр клубы һәм яшәү урыны буенча 13 хоккей корты эшли, алар яшүсмерләрнең ялын һәм мәшгульлеген оештыру, яшьләр арасында социаль тискәре күренешләрне профилактикалау һәм яшүсмерләр һәм яшьләр белән спорт-сәламәтләндерү белән шөгыльләнә. 93520 кешене җәлеп итәрлек 159 клуб берләшмәсе эшләп килә.

Муниципаль яшьләр программасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә, алдагы елларда Яр Чаллы шәһәрендә яшьләрдә актив һәм сәламәт яшәү рәвешенә, сәламәтлекне ныгыту, гражданлык позициясен, хезмәттәге һәм социаль активлыкны үстерү буенча озак сроклы максатларга ирешү өчен нигез булдырылган.

Хәзерге заман шартларында шәһәр яшьләр сәясәтенең төрле өлкәләре тирәнәйтүне һәм алга таба үсешне таләп итә, әлеге программа шуларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән булырга тиеш. Программа барлык яшь гражданнарның ихтыяҗларын, үткәрелә торган чараларның адреслылыгын исәпкә алып төзелә, яшь буынны үстерүдә уңай тенденцияләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән.

2016 ел башына шәһәрдә 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге 122 мең яшь кеше яши, шул исәптән югары белем бирү йортлары студентлары – 15828 һәм 13182 – урта һөнәри белем бирү йортлары студентлары. Яшьләр шәһәрдә яшәүчеләрнең 25 % ын тәшкил итә.

Яшьләр иҗтимагый хәрәкәтен бүләкләү өчен ел саен 20 исемле стипендия, 10 шәһәр Хакиме премиясе бирелә.

Шәһәрдә талантлы яшьләргә рухи-интеллектуаль тәрбия бирүгә һәм ярдәм итүгә аерым игътибар бирелә. Ел саен яшьләр һәм шәһәр халкы өчен «Яшьләр көне», «Җиңү көне», «Ватанны саклаучылар көне», «Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне» кебек зур чаралар үткәрелә.

Яшьләр арасында хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен хәл итүдә, тулаем шәһәр яшьләр сәясәтен тормышка ашырудагы кебек, иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр ышанычлы партнер булып тора.

Балалар һәм яшьләр хәрәкәте үсә. 6500 дән артык кешене җәлеп итәрлек 52 яшьләр оешмасы булдырылган һәм алар актив рәвештә иҗтимагый файдалы эшчәнлек алып баралар. Иҗтимагый оешмалар эшен шәһәр иҗтимагый оешмалар үзәге һәм Ирекле ярдәмне үстерү үзәге алып бара.

Шәһәрдә тәрбия эше буенча күп дәрәҗәле система эшли, ул учреждение җитәкчеләре советының ай саен үткәрелә торган киңәшмәләре, тәрбия эшләре буенча проректорлар советының атналык утырышлары аша тормышка ашырыла.

Яшьләр өчен эшкә урнашу мәсьәләсе мөһим булып тора. Хәзерге вакытта шәһәр оешмалары һәм предприятиеләре белән кадрларга ихтыяҗны ачыклау буенча эш алып барыла. Вакансияләрнең электрон мәгълүматлар базасы урнаштырылган сайт эшләп килә. Сайтта теләсә кайсы эш бирүче вакансияләр турында мәгълүмат урнаштыру мөмкинлегенә ия.

Яшьләр арасында социаль тискәре күренешләрне профилактикалау дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлеше булып тора, наркоманлык, күзәтүчесезлек һәм хокук бозуларны профилактикалау, толерантлык формалаштыру, яшьләр арасында суицидларны профилактикалау, белгечләр, ата-аналар белән эшне оештыру, тикшеренү эше, ведомствоара хезмәттәшлек кебек мөһим юнәлешләр гамәлгә ашырыла.

## 3 бүлек. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның төп максаты булып яшьләрне социализацияләү һәм үз мөмкинлекләрен нәтиҗәле тормышка ашыру өчен шартлар тудыру тора.

Әлеге максатка ирешү өчен Программа түбәндәге бурычларны тормышка ашырырга тиеш:

- Балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең ялын оештыру;
- Яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең асоциаль һәм деструктив тотышларын профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар оештыру, социаль-куркыныч хәлдәге балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү;
- Яшьләрне вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

Программаны тормышка ашыру өч елга – 2017-2019 елларга исәпләнгән.

## 5 бүлек. Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

### Программаны финанслау структурасы

| Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 1 нче ел мең сум | 2 нче ел мең сум | 3 нче ел мең сум | Барлыгы мең сум |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 117663,63 | 118026,82 | 118366,66 | 354057,11 |
| Республика бюджеты | - | - | - | - |
| Федераль бюджет | - | - | - | - |

## 6 бүлек. Программа чаралары системасы

7. Программа чаралары яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының хезмәт күрсәтүләр һәм хезмәтләр база (тармак) исемлеге, норматив документлары нигезендә билгеләнгән.

8. Программа чаралары системасы түбәндәге юнәлешләр буенча эшләрне берләштерә:

- Яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең үз-үзләрен асоциаль һәм деструктив тотышларын профилактикалауга, социаль куркыныч хәлдә булган балаларга һәм яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру;
- Яшьләр сәясәте өлкәсендә талантлы һәм инициативалы яшьләрне үстерү системасын формалаштыруга, яшүсмерләргә һәм яшьләргә үз-үзләрен реализацияләү өчен шартлар тудыруга, иҗади, һөнәри, интеллектуаль потенциалларын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру;
- Яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрдә гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләүгә, яшьләр арасында толерантлык тәрбияләүгә, хокукый, мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләрне формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру;
- Яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне инновацион, эшмәкәрлек, ирекле ярдәм эшчәнлегенә җәлеп итүгә, шулай ук яшьләрнең гражданлык активлыгын үстерүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, шулай ук яшьләрнең белем алулары өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру.

## 7 бүлек. Финанслау тәртибе һәм программаны тормышка ашыру барышын контрольдә тотуны оештыру

9. Программа үтәлешенә гомуми контрольне Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе гамәлгә ашыра, ул максатчан күрсәткечләрне, программаны тормышка ашыру механизмын, башкаручылар составын аныклый, Программаны үтәү буенча еллык эш барышы һәм финанслардан файдалануның нәтиҗәлелеге турында хәбәр итә.

## 8 бүлек. Нәтиҗәлелекне бәяләү индикаторлары

Программаны тормышка ашыру күрсәткече булып нәтиҗәлелек индикаторлары белән үлчәнә торган максатка ирешү тора:

| № т/б | Күрсәткечләрнең исеме | Хисап формуласы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Программа клуб берләшмәләре һәм программа белән җәлеп ителгән 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге мәшгуль яшьләрнең чагыштырма авырлыгы, яшьләрнең гомуми санына карата, % | $C = \frac{C1 \times 100\%}{C2}$ монда C1 – программа һәм клуб берләшмәләре белән җәлеп ителгән кеше саны C2 – Яр Чаллы шәһәрендәге 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләрнең гомуми саны | Яшьләр белән эшләү учреждениеләренең муниципаль йөкләмәләрен тормышка ашыру турында хисабы, яшьләр сәясәте учреждениеләре хисабы |

## 9 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелек күрсәткечләре

12. Программаны практик тормышка ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

1) шәһәрнең уңай социаль-икътисадый үзгәрешләрендә яшьләрнең ролен арттыру;

2) яшь гаилә институтын ныгыту, яшьләрнең торак-көнкүреш шартларын яхшырту;

3) яшьләрнең интеллектуаль, әхлакый һәм иҗади потенциалын арттыру, милли үзаңын, гражданлык һәм патриотизмны үстерү;

4) хезмәт, мәшгульлек һәм яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү базарында яшьләрнең конкуренциягә сәләтен арттыру;

5) яшь буында сәламәт яшәү рәвешенә юнәлеш формалаштыру;

6) яшьләр арасында җинаятьчелек, эчкечелек һәм наркомания дәрәҗәсен киметү;

7) яшь гражданнар өчен мәгълүмати хезмәтләрне киңәйтү;

8) яшьләрнең эшлекле активлыгын һәм булдыклылыгын үстерү;

9) яшьләрдә актив тормыш позициясе һәм шәһәрнең иҗтимагый-сәяси тормышында катнашуга әзерлеген формалаштыру;

10) шәһәр яшьләренең гражданлык үсеше һәм үз-үзләрен социаль реализацияләү өчен уңайлы шартлар тудыру;

13. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып яшьләрнең җәмгыятьтәге социаль-икътисадый хәлен яхшырту, яшьләр арасында социаль-тискәре күренешләрне киметү тора.

Максатлар, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләүнең индикаторлары һәм 2017-2019 елларга муниципаль яшьләр программасын чаралар буенча финанслау

| Бурычның исеме | Эшчәнлекнең төп юнәлешләре исеме | Башкаручылар | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләүнең индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зрлыгы | | | | Финанс чыганагын күрсәтеп, финанслау | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 база | 2017 | 2018 | 2019 | 2016 база | 2017 мең сум | 2018 мең сум | 2019 мең сум |
| Максат: Яшьләрне социализацияләү һәм аларга үз-үзләрен нәтиҗәле реализацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | | |
| Программа клуб берләшмәләре һәм программа белән җәлеп ителгән 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге мәшгуль яшьләрнең чагыштырма авырлыгы, яшьләрнең гомуми санына карата, % | | | | 76.6% | 76.5% | 76.5% | 76.5% | - | - | - | - |
| Балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең ялын оештыру | Программаларны, проектларны һәм клуб берләшмәләрен тормышка ашыру | «Шатлык» яшьләр үзәге» МАУ; «Яшүсмер» яшүсмерләр-яшьләр клублары үзәге» МАУ; «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» МБУ; «Заман» яшьләр үзәге» МАУ; | Тормышка ашырылган программалар, проектлар һәм клуб берләшмәләре саны, данә<br><br>Программаларга җәлеп ителгән кешеләр саны, кеше. | 159<br><br>93520 | 159<br><br>93520 | 159<br><br>93520 | 159<br><br>93520 | 85020,9 | 99615,3 | 99978,5 | 100318,3 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең асоциаль һәм деструктив тотышларын профилактикалауга, социаль куркыныч хәлдә булган балаларга һәм яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру; | Чаралар үткәрү | «Орион» яшьләр үзәге» МАУ; «Яшьләр ышаныч телефоны» экстрен психологик ярдәм үзәге» МБУ; «Диалог» психологик-педагогик ярдәм үзәге МБУ; «Укучы һәм студент яшьләрне эшкә урнаштыру үзәге» МАУ | Чараларга килүчеләр саны, кеше | 116482 | 116482 | 116482 | 116482 | | | | |
| | Телефон аша психологик консультацияләр үткәрү | «Яшьләр ышаныч телефоны» экстрен психологик ярдәм үзәге» МБУ | Телефон аша психологик консультацияләр, данә | 6000 | 6000 | 6000 | 6000 | 5100,4 | 5394,6 | 5394,6 | 5394,6 |
| | Индивидуаль һәм психологик-педагогик эш (консультацияләр) үткәрү | «Диалог» психологик-педагогик ярдәм үзәге МБУ | Индивидуаль психологик-педагогик эш, төркемле психологик эш формалары белән колачланган | 222 | 222 | 222 | 222 | 4911,5 | 5502,3 | 5502,3 | 5502,3 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | кешеләр саны, кеше | | | | | | | | |
| | Яшьләр сәясәте активистларын шәһәр Хакименең исемле стипендияләре белән бүләкләү | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | Яшьләр сәясәте өлкәсендә адреслы ярдәмнән файдаланган лидерлар һәм белгечләр саны, кеше | 40 | 20 | 20 | 20 | 480,0 | 480,0 | 480,0 | 480,0 |
| | Яшьләр сәясәте өлкәсендәге иң яхшы хезмәткәрләргә Хаким премияләре бирү | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | Яшьләр сәясәте өлкәсендә адреслы ярдәмнән файдаланган лидерлар һәм белгечләр саны, кеше | 10 | 10 | 10 | 10 | 130,2 | 260,4 | 260,4 | 260,4 |
| | Шәһәр чаралары, конкурслар һәм фестивальләр үткәрү, республика һәм Бөтенроссия конкурсларында һәм чараларында катнашу | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | Чараларга килүчеләр саны, кеше | 1300 | 1300 | 1300 | 1300 | 920,0 | 659,6 | 659,6 | 659,6 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру | Яшүсмерләрне һәм яшьләрнең мәшгульлеген тәэмин итү; вакытлыча эшкә урнашуны оештыру | «Укучы һәм студент яшьләрне эшкә урнаштыру үзәге» МАУ | Вакытлыча эшкә урнаштырылган 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр саны, кеше | 1213 | 1213 | 1213 | 1213 | 7964,7 | 5751,4 | 5751,4 | 5751,4 |
| барлыгы: | | | | | | | | 104397,5 | 117663,63 | 118026,82 | 118366,66 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова